КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 август г.Казань № 742

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алабуга-2. Нефтехимия» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 август, 783 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 октябрь, 947 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) белән расланган «Алабуга-2. Нефтехимия» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алабуга-2. Нефтехимия» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә «Алабуга-2. Нефтехимия» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын төзү,

модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга 2021 ел, 27 август, 783 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 октябрь, 947 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) белән расланган (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктта:

бишенче абзацта «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе мәгънәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

17 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, ә дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

21 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Тәртипнең 5 пунктындагы өченче абзацының, 8 пунктындагы дүртенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы тугызынчы абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин